# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына өстәмә кертү турында**

1 статья. «1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998 ел, №12; 1999 ел, №6, № 9) түбәндәге редакциядә җиденче өлеш өстәргә:

«1999 елның 1 гыйнвареннан Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең хуҗалык идарәсен Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелә торган өлешендә өстәлгән бәяләргә салым түләүдән һәм Татарстан Республикасының Юллар фондына салымнардан азат итәргә».

2 статья. Әлеге Законны рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1999 елның 16 ноябре
№ 2427